# КАРАР

**06 июнь, 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 06 июнендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

- 2 нче пунктта:

беренче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иске Юмья авылында сууткәргеч челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү системаларын, артезиан скважинасын, ВНБны ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларга вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);
- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау һәм карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 477 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 261 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 261 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы мәсьәләсе буенча карарны:

- 2 нче пунктта:

беренче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иске Юмья авылында сүүткәргеч челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү системаларын, артезиан скважинасын, ВНБны ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларга вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сүүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү);

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау һәм карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сүүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Оштырма Юмья авыл
җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев